

Ак
бүре

Ак бүре

татар халык әкияте

КЫЯМ МИҢНЕБАЕВНЫҢ
әдәби эшкәртүендә


Рәссам
ФӘРИДӘ ХӘСЬЯНОВА



«ЗАМАН» НӘШРИЯТЫ
КАЗАН
1993

КАЗАНСКАЯ ЦЕНТРАЛИЗОВАННАЯ
БИБЛИОТЕЧНАЯ СИСТЕМА





Бу китап Казандагы Г. Тукай музееның беренче директоры
Госман Әкрәм улы Хәбибуллинның якты истәлегенә багышлана

Борын заманда булган, ди, бер падишаһ. Көннәрдән бер көнне бу, алтын арбасына яхшы атлар җиктереп, җир йөзендә бер чибәр хатынын янына утыртып, чыгып китә, ди, сахраларга күңел ачарга. Кояш баеп, кич җиткәч, хезмәтчеләре сахра уртасына корып җибәрәләр, ди, ефәк чатыр. Алар йоклап яткан чагында, җиде төн уртасында, коточкыч җил-давыл купкан да, ди, чатырны әллә кайларга илтеп ташлаган, ди. Падишаһ уянып китсә, ни күрсен — хатыныннан җилләр искән. Хезмәтчеләре белән бергә-бергә күпме генә эзләмәсен, һич кенә дә таба алмый хатынын. Эзләп-эзләп тә һич кенә дә таба алмагач, сараена кайтып китәргә мәҗбүр була падишаһ. Аннары да әле, ат җиткән җиргә ат җибәреп, хат җиткән җиргә хат җибәреп, сөекле хатынын эзләтеп азаплана, ди.

Падишаһның дүрт улы булып, алар дүртесе дә читтә укыйлар — белем алалар икән. Падишаһның җир йөзендә бер чибәр хатыны югалып бер ел үткәннән соң кайтып төшә, ди, укуын тәмамлап, аның олы малае. Атасы янына керә дә:

— Әнине эзләргә чыгарга миңа рөхсәт бирсәңче, әти,— ди.

Әтисеннән рөхсәт алып, үзе белән йөз солдат та алып, шактый мал һәм дә азык-төлек алып, сәфәр чыга, ди, бу. Ай китеп, ел китеп, әйләнгән җирдә әйләнмә үсеп, тулганган урында кызыл тубылгылар үсеп, ташка тары, бозга бодай үсеп, аны шатыр-шотыр урып ятканда, барып җитәләр, ди, болар яман куе бер урманга. Шул урманга кереп, урманның

да эчләрендә йөреп, анда ямьле генә бер инеш буйларында матур гына алан күреп, туктыйлар, ди, болар ял итәргә.

Шаһзадәнең әмере белән, юлдашлары атларыннан төшәләр, атларын чирәмгә җибәрәләр, үзләре тиз арада чатырлар корып, ашлар пешереп, ашарга утырышалар. Шулай, болар ашарга утыргач кына, шаһзадәнең чатырына килеп керә, ди Ак бүре, сәлам биреп:

— Һәй, тәрбиясезләр, кем рөхсәте белән минем урманыма кердегез дә, кем рөхсәте белән үлән таптап йөрисез? — дип кинаясен белдерә, ди.

Һич тә уйлап-нитеп тормый шаһзадә:

— Хәзер менә күтәрелдек тә киттек, тот капчыгың! Яхшы чакта үзең сыпырт моннан, солдатларыма кушып аттыртмас борын! — дип җавап кайтара, ди.

Юньләп әйткәннең кадерен белмәгәч, үлән таптаудан туктамагач, урманнан чыгып китмәгәч, бик тә хәтере кала Ак бүренең. Һәм ул, тәмам гайрәте чигеп, бер генә әфсен укый да, боларның өсләренә бер генә өрә — падишаһның олы малае һәм дә аның йөз солдаты, барчасының атлары шундук тораташка әйләнә, ди.

Олы улыннан хәбәр көтә падишаһ. Биш ай көтә, алты ай көтә, бер ел көтә. Нәкъ шул вакыт падишаһның уртанчы уллары кайтып төшә мәдрәсәдән. Хәл-әхвальләр белешкәннән соң, болары да:

— Әнине эзләргә инде без чыгыйк, — диләр, әтиләреннән фатиха сорыйлар.

Падишаһның боларга бер дә инде менә фатиха бирергә исәбе юк:

— Абзагызның киткәненә бер ел булды, һич хәбәр-хәтере юк. Инде сезне дә югалтыйммы?! — ди.

Ләкин уллары падишаһның күзен дә ачырмыйлар, һаман да фатиха даулыйлар. Шуннан падишаһның чыдамы сына — бирсә дә бирә сәфәргә рөхсәт, бирмәсә дә бирә сәфәргә рөхсәт.


— Мәгәр бер елдан артык эзләтергә һич ризалыгым юк! — дип сүзен тәмамлый падишаһ.


Бер дә бер көнне ике туган, аталарыннан йөзәр атлы солдат алып, бер елга җитәрлек азык-төлек алып, ике йөз дә ике кеше булып кузгалалар болар сәфәргә. Иртә китәләр, кич китәләр, бик күп сүзләр сөйләнә, итәкләре җирдән сөйрәлә, ат өстенә ятып, агач мылтыклардан атып, муеннары аладай, чырайлары турадай[1] булган бер заманны барып җитәләр,



[1] тура — эремчек кабартмасы

ди, болар әлеге дә баягы карурманга. Шул урманга кереп, урманның эчләрендә йөреп, анда ямьле генә бер инешнең буйларында матур гына алан күреп, туктыйлар, ди, болар, ялга. Атларыннан төшәләр дә атларын үләнгә җибәрәләр, үзләре тиз арада





чатыр корып, ашлар пешереп, ашарга утыралар. Шулай, болар ашарга утырышкач кына, шаһзадәләр чатырына килеп керә, ди, Ак бүре.

— Кем рөхсәте белән монда килдегез дә шул чаклы солдат белән, шулчаклы атлар белән урманымда үлән таптап йөрисез? — дип кинаясен белдерә.— Һич рөхсәтем юк! — дип, боларны куа да башлый.

Әмма тегеләрдән:

— Хәзер менә, күтәрелдек тә киттек, тот капчыгың! — дигән маса-юлы җавап ишетә.

Кабат-кабат әйтеп тә, яхшылык белән китә белмәгәч, үгетләүгә колак салмагач, тәмам гайрәте чигеп, Ак бүре янә әфсен укып өрә дә — болар барчасы тораташка әйләнә, ди.

Инде янә килик падишаһның үзенә. Җир йөзендә бер чибәр хатыны гаип булганга өч ел, аннары олы малае китеп югалганга ике ел, уртан-чыларына бер ел дигәндә, мәдрәсәдә укуларын тәмамлап, кайтып төшә, ди, падишаһның кече улы, төпчеге. Әтисеннән хәл-әхваль сораша бу, абзыйларының язмышлары белән кызыксына.

Падишаһ аңа:

— Һичбер хәбәр-хәтерләре юк бит...— дип җавап кайтара.

Төпчек малай бер дә уйлап тормый:

— Берәр хәл булгандыр үзләренә. Барып эзләп карамыйча ярамас. Инде миңа да бирсәң иде фатиханны,— ди.

Падишаһ:

— Инде төпчек улымнан да язсам, аннары мин нишләрмен? Һич ризалыгым юк! — дип каршы торып караса да, көн-төн фатиха сорап



төмам теңкәсенә тигәч, ата кешенең күңеле йомшара — шуннан инде бирсә дә бирә сәфәргә рөхсәт, бирмәсә дә бирә сәфәргә рөхсәт.

— Әткәй, миңа синнән гаскәр дә, азык-төлек тә кирәкмәс, фәкать бераз акча гына алырмын юлга,— ди төпчек малай.

Бик шәп атка атланып, Аллага тапшырып, сәфәр чыга шаһзадә. Күпмедер ай, күпмедер көн, күпмедер сәгать барганнан соң бу да юлыга, ди, әлеге дә баягы карурманга. Су буендагы ямьле аланга җиткәч, атын бераз ял иттерергә, аз-маз тамак ялгап алгаларга ниятләп, иярдән сикереп төшә дә бу атның тезгенен бер зирекнең ботагына бәйләп куя, аннары мылтыгын алып кош-корт ауларга урман эченәрәк юнәлә. Биш-ун адым атларга да өлгерми — әлеге дә баягы Ак бүрегә тап була.

— И, егеткәй, син нишләп йөрисең, кайлардан киләсең, кайларга барасың? Монда минем рөхсәтемнән башка аланда үлән таптау җитмәгән, кошлар да ауламакчы буласың икән әле,— ди Ак бүре.

Шаһзадә әдәп белән генә:

— Әнә ул кошны атып алып, учакта кыздырып ашармынмы дигән идем. Бик ерак җирләрдән килдем, бик тә арыдым. Ярар, алайса, синнән узып, берни дә эшләмим, кошыңа да тимим! Әнә күрәсең атымның башын югары күтәреп бәйләп куйдым. Тезгенен чишәм дә, урманыңнан чыгам да китәм,— дип җавап кайтара.

Моны ишеткәч тә, йомшара Ак бүре:

— Егетем, үзең ямьле икәнсең, сүзең дә тәмле икән, күңелемә бигрәкләр инде хуш килдең. Әйтер сүзем шул сиңа: урманымда йөрергә, атыңны ашатырга, кошларымны атарга рөхсәт бирәм. Тик менә бу

кошны атма син. Әнә теге дәү имәннең башында бер кош утыра, бар да шуны атып ал. Аш пешерсәң, мин дә килермен, кунак булырмын, сыйланырмын,— ди дә үз юлына китеп бара.

Ак бүренең сүзен тыңлап, әлеге дәү имәнгә якынрак килә шаһзадә, имән башындагы кошны күрә, күкрәгенә төзәп, мылтыгының чакмасын тартып та җибәрә. Кош әйләнеп килеп төшкәч, аны ала да аты янына кайта шаһзадә. Атын үләнгә җибәреп, үзе чатыр кора, ашарга пешерә дә Ак бүрене көтәргә керешә.

Һич уйламаганда моның чатыры янында яшь кенә бер егет пәйда була, моңа хөрмәт белән сәлам бирә. Чит кунакны ачык чырай белән каршы ала шаһзадә, чатырына чакыра, хәзинәсендә бар сыен куя. Кунакны кыстый-кыстый сыйлый торгач, табындагы ризыкны ашап бетерә язалар. Шунда гына шаһзадәнең исенә келт итеп Ак бүре килеп төшә: «Инде аңа нәрсә куярмын?» — дип хафалана да борчыла.

Кунак егет моның хафалануын күреп:

— И дустым, яхшы гына, күңелле генә утырган җирдән әллә нигә күңелсезләнеп киттең әле. Нинди хәсрәт төште башкаеңа? — дип сорап куя.

Шаһзадәнең шуннан урманда Ак бүрегә тап булуын, аның рөхсәте белән имән башындагы кошны атып алуын, аш пешереп, Ак бүрене көтеп торуын сөйләп бирми хәле юк.

— Инде ни белән сыйлармын ул Ак бүрене? — дип сүзен тәмамлый шаһзадә.

Моны ишеткәч кунак егет:

— Әй дустым, юкка гына кайгырасың икән ләбаса! Бая бүре булып сиңа мин күрендем. Җитмеш төрле һөнәрем бар, җитмеш төрле сурәткә дә керә алам,— ди.

Шуннан соң бөтенләй тынычланып, күңелләре ачылып, үзенең кем икәнлеген, әнкәсенең юкка чыгуын, агаларының аны эзләргә китеп тә әйләнеп кайтмавын һәм үзенең дә нинди ният белән сәфәр чыгуын бәйнә-бәйнә сөйләп бирә шаһзадә.

Моны ишеткәч:

— Инде, дустым, агаларың хәзерге көндә исән-сау дип уйлыйсыңмы? — дип кызыксына Ак бүре.

Күзен дә йоммый шаһзадә:

— Исән-сау булырга тиешләр. Чөнки алар бозык юлга, яман ният белән киткән кешеләр түгел. Өч агамның өчесенең дә йөзәр атлы солдаты да бар бит әле,— ди.

Моңа каршы Ак бүре:

— Соң син ул агаларыңны күрсәң таныр идеңме? Әйдә әле монда, үзеңне бер җиргә алып барыйм,— дип, иң



олы агасының torаташ булып каткан җиренә алып бара.
Шунда алып барганнан соң, өстенә күкле-яшелле мүкләр үсеп беткән ташка ымлап:

— Менә бу нәрсә, таныйсыңмы?—дип сорый.—Алай булгач, танымасаң, мин әйтим: менә бусы синең өлкән агаң, әнә ул, янында яткан ташлар—аның батыр солдатлары. Яхшылап әйткәнне аңламагач, үземә янап маташкач, аларны шушы сурәткә кертергә мәҗбүр булдым,—дип төшендереп бирә Ак бүре.

Мүкләнеп беткән әлеге ташларның агасы һәм аның солдатлары икәнен белгәч, күңеле нечкәреп китә шаһзадәнең, һәм ул елап җибәрә. Аларны әүвәлге кыяфәтләренә кайтаруын сорап, Ак бүрегә ялвара.

Ак бүре аңа:

— Ярый, синең хакка аларны мин әүвәлге кыяфәтләренә кайтарам. Мәгәр синең бу агаң да, аның кешеләре дә сиңа юлдаш булырга ярый торганнардан түгел. Терелгәч тә, син аларны тиз генә шәһәрегезгә кайтарып җибәр,—ди.

Шуннан соң Ак бүре, тискәре якка карап, әфсен укый, аннары ташларның өсләренә өреп җибәрә—тегеләргә шундук җан керә, сикерешеп торалар да һәммәсе үзенең бүленеп калган эшенә тотына: кайсы мылтыгын караштыра, кайсы атын иярли, кайсы тәмәке төрә. Падишаһның олы улы ашыктыра:

— И егетләр, тизрәк булыгыз! Бик озак йоклаганбыз, ахры, тизрәк юлыбызга кузгалыйк!—дип әмер бирә.

Шул чагында аның янына ике егет килеп сәлам бирә. Бик һәйбәтләп күрешәләр болар. Агасы моны танымаганны күреп-абайлап, падишаһның төпчек улы:

— И агай, мин бит синең иң кече энең булам. Мин укыган чакта сез әнине эзләргә дип киткәнсез дә, ничә елдан бирле сез кайтмагач, һичбер төрле хәбәрегез килмәгәч, әти мескен елый-елый күзсез калды. Инде мин дә, әтидән фатиха алып, әнине эзләргә дип сезнең арттан сәфәр чыктым. Шушы урманга җитеп, Ак бүрегә юлыктым. Аның белән дуслашып, сезнең хәлне дә белдем. Яхшылап әйткәнне аңламыйча, Ак бүрегә карышып, үзегезне үзегез һәлак иткәнсез! Инде менә хәзер, минем сүземне тыңлап, Ак бүре һәммәгезне әүвәлге сурәтенә кайтарды. Исән-имин хәлдә өйгә юл тотуыгыз хәерлерәк булыр,—ди.

Бу сүзләрне ишеткәч тә, агасы үз гаскәре белән бергә өйләренә юнәлә.

Падишаһның төпчек улы уртанчы агалары янына барып, Ак бүредән аларны да әүвәлге сурәтләренә кайтаруын

үтенә. Гәрчә аның сүзен тыңласа да, Ак бүре боларны да юлдаш итеп алырга ярамаганын аңлата:

— Бик кирәк дисең икән инде, үзеңнән бер яшь олы агаңны алып калырсың. Башкалары синең эшкә ярамаслар, кайтып китсеннәр,— ди.

Шуннан Ак бүре, баягы кебек әфсен укып, боларны да терелтә. Болары да, олы агасы шикелле үк, саубуллашып туган шәһәрләренә кайтып китә. Падишаһның төпчек улы янында үзеннән бер яшькә олы агасы гына торып кала.

Агасы һәм Ак бүре белән бергә-бергә янә чатырга әйләнеп кайткач, падишаһның төпчек улы:

— Йә, инде, Ак бүре, мин юл кешесе, юл кешесенең юлда булуы хәерле. Син мине тотма, урманыңнан чыгып китәргә рөхсәт бир,— ди.

Моны ишеткәч, Ак бүре:

— Миннән рөхсәт. Мәгәр үзегезне озата барырмын. Югыйсә урманда хәйран усал җанварлар бар, зарар китермәгәйләре,— ди.

Шулай итеп урманны чыкканчы аларны озата бара. Юлда барган арада киңәшләрен бирә Ак бүре:

— Минем урманны чыккач та, өч көн, өч төн баргач та, дию патшасының җиренә җитәрсез. Янә дә өч көн, өч төн барганнан соң алтмыш колач юанлыгы алтын тирәккә юлыгырсыз. Ул алтын тирәкнең астында кечкенә генә бер күл булыр. Шул күлгә җиткәч тә, күл буена бер куыш казып, абзаңны шул куышта калдырырсың. Үзең исә әлеге тирәкнең бер ягына баз казып, шул базга ятып, ике күзеңне генә калдырып, үзеңне үзең күмәрсең. Берәр сәгать үткәннән соң әлеге күлгә бер көтү елкы[1] төшәр, су эчәр. Елкыларны сабыр гына карап ятарсың. Ул елкылар менеп киткәч тә, янә берәр сәгать үткәч тә, күкләр күкрәтеп, җирләр җимертеп, өермәләр өереп, алтмыш чакрымнан тояк тавышлары ишетелеп, бер Алтмыш колачлы ала айгыр ыжгырып килер дә, алтмыш колачлы алтын тирәкнең бер ягына ялын ышкый башлар. Ялын ышкып арыганнан соң, яман сусап, әлеге күлнең суын эчәр, бөтенләй эчеп бетерер дә әлеге агачка килеп, икенче як ялын ышкырга тотыныр. Шул вакытта күлдә су беткәнлектән, күлнең төбендә балыклар җыелышып калыр, агаң шуларны куышына ташып куяр — үзенә азык булыр. Озаклап ышкына торгач, Алтмыш колачлы ала айгыр алтмыш колачлы алтын тирәкне сындырыр. Аның шатыр-шотыр сынган тавышына базыңнан ялт кына чык та, шул Алтмыш колачлы ала айгырның сыртына атланырга тырыш. Сыртына атлана

[1] Елкы — иркендә йөрүче ат.


алмыйсың икән, ялына ябыш. Инде ялына да ябыша алмаган очракта — ичмасам койрыгына ябыш. Аннан соң айгырдан аерылмаска тырыш: ул утка керә икән — утка кер, суга керә икән — суга кер, ябышкан җиреңнән кулыңны ычкындыра күрмә. Әгәр ычкындырсаң — шул мизгелдә һәлак булырсың. Әгәр дә инде иксез-чиксез михнәтләргә түзәсең икән — шул чагында әниеңне табарсың,— ди.

Падишаһның төпчек улы:

— Инде мин ни күрсәм дә күрермен, һәммәсенә түзәрмен. Анамның юлында йә корбан булырмын, йә эзләп табармын,— ди.

Ак бүре аңа каршы:

— Ярый, дустым, болай булгач, табуыңа да ышанамын. Тапкан тәкъдирдә юл уңаеннан минем яныма керми китә күрмә. Урманымның теләсә кай җиренә туктарсыз, атларыгызны ял иттерерсез, үзегез җаныгыз теләгән киекне атып алып сыйланырсыз. Әмма кунак булмыйча китсәгез, һич ризалыгым юк. Инде бер килеп урманыма төшкәч, кая гына туктасагыз да абайлармын, сезне үзем табармын,— ди.



Кунаклар, Ак бүре белән саубуллашып, аның урманыннан чыгып китәләр.

Өч көн, өч төн барганнан соң, болар дию патшасының җиренә килеп керәләр. Янә дә өч көн, өч төн барганнан соң әлеге дә баягы алтын тирәкне күрәләр. Икәүләшеп тиз генә күл буена берәр баз казып, күзләрен генә елтыратып калдырып, шунда үзләрен күмеп куялар. Ак бүре әйткән раска килә: бер көтү елкы төшә дә сулар эчеп, үлән ашарга яр башына юллана. Берәр сәгать үткәннән соң, зилзиләләр кубарып, күкне күккә селтәп, җирне җиргә бәреп, өермәләр өереп, Алтмыш колачлы ала айгыр күл буена килеп төшә. Килеп төшүе була, алтмыш колачлы алтын тирәккә ялын ышкый башлый, аннары су эчәргә керешә — күлнең суын тәмам эчеп бетерә, аннан инде икенче як ялын ышкырга тотына. Моның ышкуына чыдый алмыйча, бер заман алтмыш колачлы алтын тирәк төбеннән үк шартлап сына. Шул чакны шаһзадә баздан атылып чыга да Алтмыш колачлы ала айгыр-



ның ялына чытырдап ябыша. Ник ялына гына дигәндә, айгыр гаҗәп биек була, аның сыртына атланырга буе җитми кала. Алтмыш колачлы ала айгыр ялына адәми зат ябышканын шундук абайлап ала, шуннан бер җиргә түндереп, бер күккә чөереп, тау-ташларга бәрә-бәрә, китә моны җилтерәтеп. Шулай бәрелеп-сугылып бара торгач, бер заман килеп җитәләр болар ут тавына. Алтмыш колачлы ала айгыр ут тавының янына туктый да болай ди:

— И егеткәй, инде кулыңны ычкындыр. Мин хәзер бу ут тавының аргы ягына чыгамын. Аны аркылы чыккан чакны синең һәммә җирең көеп, янып бетәр,— ди.

Шаһзадә моңа каршы:

— И айгыр, мин янган-көйгән җирдә син дә бит исән калмассың,— дип җавап кайтара да ычкындырмый кулын.

Алтмыш колачлы ала айгыр гайрәтләнеп ут эченә кереп китә, ике-өч сәгать буена егетне өстерәп йөртә-йөртә дә ут тавының аргы ягына алып чыга. Шаһзадәнең тәннәре пешә, куырыла, әрни, шулай да ул сер бирми.

Ә бер заман артына борылып караса — бернинди дә ут тавы юк, имеш. Бу хәлне күргәч, ут тавы дигән нәрсәнең фәкать күз буяу гына икәненә тәмам инангач, ала айгырның ялына тагы да ныграк ябыша.

Алтмыш колачлы ала айгыр исә:

— И егеткәй, инде кулыңны ычкындыр,— дип үгетли.

Шаһзадә әйтә:

— Юк, ычкындырмыйм. Син кая барсаң, мин дә шунда барам,— ди.

Шулай низагълашып бара торгач, килеп җитәләр болар олы бер диңгезгә. Алтмыш колачлы ала айгыр янә кабатлый:

— Инде, егеткәй, ычкындыр кулыңны. Ут тавыннан котылсаң да, бу диңгездән котыла алмассың. Мин диңгез кичкәндә, авыз-борыныңа су тулып, тончыгып үләрсең,— ди.

Шаһзадә моңа каршы:

— Минем синнән аерыласым юк. Син кая барсаң, мин дә шунда барам. Минем авызыма-борыныма тулган су синекенә дә тулар. Үлсәк, бергә үләрбез,— дип җавап кайтара.

Алтмыш колачлы ала айгыр, яман гайрәтләнеп, егетне диңгезгә өстерәп алып кереп китә. Өч көн, өч төн йөзгәннән соң диңгез аръягына барып чыга. Анда да әле, егетне тончыктыру нияте белән, башын болгый-болгый, суга чумыра-чумыра баруын белә. Әмма егеткә һичбер зыян китерә алмый.

Коры җирдән бераз барганнан соң килеп җитәләр болар

яман куе бер урманга. Гаҗәеп куе урман икән — чыпчык үтәрлек тә урын юк икән.

Алтмыш колачлы ала айгыр шаһзадәгә:

— И егеткәй, алдыбызда кара урман. Шуны ватып-җимереп аргы ягына чыгачакмын. Инде син миннән кулыңны ычкындыр. Югыйсә агачларга сугылып-ботарланып бетәрсең, бары тик миңа ябышкан кулларың гына калыр,— ди.

Шаһзадә моңа каршы:

— Үлсәм үләрмен, һичбер ычкындырасым юк. Мин ботарланган җирдә син дә коры калмассың,— дип җавап кайтара.

Алтмыш колачлы ала айгыр, яман хәтәр гайрәтләнеп, карурманга алып кереп китә егетне, агачларга әрле-бирле суккалап, харап итмәкче була, ничек тә котылмакчы була. Әмма һичбер төрле зыян килми шаһзадәгә.

Өч көн, өч төн үткәннән соң болар мең бәла белән карурманның аргы ягына барып чыгалар. Азмы-күпме китәләр дә килеп җитәләр, ди, болар бик биек тау-таш араларына.

Алтмыш колачлы ала айгыр әйтә шунда:

— Йә, инде хәзер кулыңны ычкындыр, шунда торып кал, юкса үләрсең,— ди.

Шаһзадә моңа каршы:

— Үлсәм үләрмен, һичбер ычкындырасым юк, дип җавап кайтара.

Шуннан Алтмыш колачлы ала айгыр, тәмам гасабиланып, моны бер тауга бәреп, бер ташка орып, өч көн, өч төн сөйрәп барганнан соң ялан кырга алып чыга. Ачуы бөтенләй сүрелеп, болай дип сүз куша:

— Инде, егетем, күп нәрсәләр күрдең. Бу сулар, утлар, таулар — барысы да дию патшалыгына адәм үтеп кермәсен өчен эшләнгән. Инде сынауларны уздың, афәтләрдән котылдың, хәзер өстемә менеп атлансаң да була. Мин сине бара торган җиремә кадәр алып барыйм инде,— ди.

Шаһзадә, ниһаять, Алтмыш колачлы ала айгырга һәйбәтләп менеп атлана да чаптырып китә. Янә дә өч көн, өч төн үткәннән соң, әллә күпме җирләр кичкәннән соң Алтмыш колачлы ала айгыр ком тавына җитеп туктап кала.

— И юлдашым, и дускаем, инде моннан ары барырга миңа рөхсәт юк. Син инде минем өстемнән төш тә ком тавының аръягына чыгарга тырыш. Ул ком тавының артында Каф тавы булыр. Каф тавының аръягында береннән-бере зәһәр диюләр, усал арысланнар, явыз аждаһалар ята. Шулар янына чыга алсаң, табарсың анаңны,— ди.

Күп итеп рәхмәтләр әйтеп, ат өстеннән төшә дә шаһзадә тауның итәгендә торып кала, Алтмыш колачлы ала айгыр исә үз юлына китеп бара.

Шуннан соң бераз тамак ялгап ала да шаһзадә тауга менмәкче була. Әмма ком ишелеп, янә түбән шуып төшә. Әнә шулай бер менеп тә, бер төшеп азаплана торгач, бу бичара тәмам хәлдән тая, анасын уйлап, ни хәл итәргә дә белмичә, елап җибәрә. Нәкъ шул чагында күк йөзендә бер кара болыт күреп, моның коты алына. Кара болыт моңа якыная башлагач, кара болыт дигәненең гаҗәеп зур кош икәнен шәйләп ала. Кош пырылдап әйләнә дә моның янына килеп төшә.

— И, егетем, әйдә менеп утыр өстемә, үзеңне бер җиргә алып китим,— ди.

Утырырга да белми шаһзадә, утырмаска да: утырсаң да — һәлак итәр, утырмасаң да һәлак итәр, дип шикләнә, әмма башка чара калмагач, тәвәккәлли бу. Шуннан әлеге кош моны күз күреме җиргә алып менеп китә.

— И егетем, әллә шүрлисең инде? — дип сорап куя.

Шаһзадә, билгеле инде:

— Шүрлим шул,— ди, дөресен әйтә.

— И дустым, мин барында бернигә дә исең китмәсен. Син үзеңнең егетлегең аркасында әллә нинди куркынычлардан котылдың. Ала айгыр белән ком тавына кадәр килгәндер дә, тауга менә алмый торадыр, дип Сәмруг кош сурәтенә кердем дә бире килдем. Иске дустың мин, Ак бүре. Мин сине хәзер Каф тавы башына илтеп куярмын, аннан ары барырга миңа рөхсәт юк,— ди.

Шулай итеп, Сәмруг кош егетне Каф тавы башына китереп җиткерә дә:

— Миңа монда озак юанырга ярамый, тизрәк үз юлыма юлланыйм,— дип саубуллашып, кире очып китә.

Шаһзадә тау башында бик күп ат вә адәм сөякләре күреп, хәйран-вәйран кала. Шуннан ике кулына ике ат сөяге алып, шуларга таяк итеп таянып, таудан төшә башлый шаһзадә. Өч ай дигәндә тауның аргы ягына төшеп җитә. Як-ягына күз салып, урыныннан кузгалуы була, бер көтү арыслан чыгып, моның өстенә ыргыла. Тәмам ашыйлар инде дигәндә генә, араларыннан берсе чыгып, боларга: «Тимәгез!» — дигән кебек итеп, барын да куып җибәрә.

Бу бәладән азмы-күпме котылып ятканда, янә бер кечерәгрәк кенә тауга тап була шаһзадә. Тауның башына менеп караса, ерактан ялтыраган бер нәрсәне шәйләп ала. «Бу ни булыр икән?» — дип, шул ялтыраган нәрсәгә карап юл ала. Ялтыраган нәрсәнең янына килеп җитсә, ни күрсен — дөнья зурлыгында корылган бакыр сарай, имеш!

Бакыр сарайга якынлаша да шаһзадә ишек шакый. Ишекне гаҗәеп сылу, бер бите ай, берсе кояштай, искиткеч чибәр кыз ача. Исәнләшәләр болар. Әлеге кыз, бик гаҗәпсенеп:

— И егеткәй, адәми затмы син, пәри затмы син? — дип сорый.

Шаһзадә аңа:

— Адәми затмын,— дип җавап бирә.



Моны ишеткәч тә кыз:

— Ат килсә — тоягы көя, кош килсә канаты көя торган җиргә син адәми зат булып ничек килеп җиттең? — ди.

Шаһзадә:

— Мин бик ерактан килдем, бик ачыктым, сарайга алып кереп тамагымны туйдырсаңчы,— ди.

Кыз моңа каршы:

— Алай булса, син бераз сабыр ит. Минем абыстам, диюнең хатыны — адәми заттан. Мин аңардан рөхсәт сорап чыгыйм. Ул ни куша — шуны эшләрмен,— ди.

Абыстаеның янына барып:

— И ханым-солтаным, ишек төбенә бер адәми зат килгән. Шуны сарайга кертеп, тамагын туйдырырга рөхсәт итмәссезме? — дип сорый.

Абыстае аңа:

— Адәми зат булса, керт, ашат, рөхсәт,— ди.

Шуннан кыз ишеккә барып, шаһзадәне кертеп, абыстай янына алып килә. Шаһзадә сәлам биреп, абыстай белән күрешә. Абыстай кунакны түргә утыртып, кызга ризык-тәгам китерергә куша. Кыз шул заман төрле кош итләре куырып китереп кунакка сый-хөрмәт күрсәтә. Шуннан соң абыстай аның янына килә дә:

— И егетем, син кайдагы кеше буласың, нинди җирләрдән килдең? — дип сораштыра башлый.

Шаһзадә:

— Мин фәлән мәмләкәттән, фәлән падишаһ улымын. Мин укуда чакта әнкәебез гаип булган иде. Әткәйдән фатиха алып, әнкәйне эзләргә чыктым, менә бу җирләргә җиттем дә, инде кая барырга да аптырап калдым,— дип үзенең хәлен сөйләп бирә.

Абыстай шуннан соң:

— Инде төшендем, ерак җирләрдән күп михнәтләр күреп килгән икәнсең. Әгәр дә анаңны табып алып кайта калсаң, минем сараема кереп кунак булмый китмә. Бу сарайның иясе җиде башлы дию җиде айлык юлга китте. Әгәр дә тиз көннән кайта алсаң, һич курыкма, кунак булып чыгарсың,— ди.

Шаһзадә керергә вәгъдә бирә.







Абыстай янә:

— Мин синең коры сүзеңә ышанмыйм. Син ананны тапкан шатлыгыңнан мине онытырсың. Менә мин сиңа үзеңә ишек ачкан кызны никахлап бирим дә, ул монда калсын. Шуны исеңә төшереп, керми китмәссең,— ди.

Шаһзадә моңа риза була. Әмма өч көн, өч төн кунак булгач, агасы исенә төшә дә:

— Мин монда рәхәттә ятамын, агамның ризыгы беткәндер дә аптырап ята торгандыр. Инде мин бара торган җиремә җитим,— дип, абыстайдан рөхсәт сорап, бикәче белән саубуллашып, юлга кузгала.

Әлеге бакыр сарайдан чыгып, өч көн, өч төн барганнан соң бу бер көмеш сарайга килеп җитә, ишек шакый. Ишекне бер кыз ача. Исәнләшәләр болар.

Кыз аңардан:

— Адәми затмы син, пәри затмы син?— дип сорый.

Шаһзадә:

— И кардәш, адәми затмын. Бик ерактан килдем, бик ачыктым, сарайга алып кереп, бераз ашатсаңчы,— ди.

Кыз моңа каршы:

— Минем өлкән абыстаем бар, аңардан рөхсәт сорыйм әле,— дип кереп китә.

Абыстае янына барып:

— Ханым-солтаным, юлдан арып бер адәми зат килгән, кертеп бераз ашатырга сорыйдыр,— ди.

Абыстае рөхсәт биргәч, шаһзадәне кертеп сыйлый. Хәл-әхваль сораша торгач, бу үзенең падишаһ баласы булуын, анасын эзләргә чыгуын бәйнә-бәйнә сөйләп бирә.

Шуннан соң абыстай моны бик әйбәтләп кунак итә.

Шаһзадә боларда өч көнләп кунак булгач, агасы исенә килеп төшә дә:

— Монда болай озаклап юану ярамас,— дип, юлга җыена башлый.

Абыстай исә:

— Кайтканда минем сараема сугылмый калма,— дип, озатып кала.

Көмеш сарайдан чыгып, өч көн, өч төн барганнан соң килеп җитә шаһзадә бик зур алтын сарайга. Сарай тирәсендәге бакчаларның матурлыгына хәйран калып, бераз торганнан соң ишек шакый.

Бер кыз моңа ишек ача. Исәнләшәләр болар. Шуннан кыз сорый егеттән:

— Адәми затмы син, пәри затмы син? — ди.

Шаһзадә үзенең адәми зат икәнен белдерә.

Абыстаеннан рөхсәт алып, кыз моны сарайга, туры абыстае янына алып керә. Әдәпле генә күрешеп, күрсәткән урынга утырып, китергән кош итләрен ашап, китергән эчемлекләрне эчкәннән соң абыстайга карап сорау бирә шаһзадә:

— И абыстай, син кайсы илдән буласың? — ди.

Абыстай:

— Мин фәлән падишаһның хатыны буламын, фәлән шәһәрдән дию урлап алып килде. Инде минем югалганыма фәлән ел булды. Алма кебек дүрт улым калды, инде алар да үсеп, синең кебек булганнардыр,— ди.

Шул чагында шаһзадә:

— Улларыңның берәрсе бу җирләргә килсә, таныр идеңме соң? — дип кызыксына.

— Әлбәттә, таныр идем, кеше үз баласын танымый димени.

— Соң, алай булгач, мин кем булам?

— Белмим шул.

— Соң мин бит синең улың буламын. Фәләнчә айдан бирле сине эзлимен. Аллага шөкер, инде нурлы йөзләреңне күрдем,— дип, егет анасының муенына барып сарыла.

Сорашып-сайрашып та, елашып-сыкташып та алалар болар. Шуннан соң абыстай улын алып чыгып, бер сарай янына ияртеп килә дә, сарайның ишеген ачып кертеп





җибәрә, сарай уртасында яткан шарны алып чыгарга куша.

Алып чыкмакчы булып, шарга тотынып карый да бит егет, әмма шарны урыныннан да кузгата алмый: шарның авырлыгы биш йөз пот, имеш. Анасы бу хәлне күреп:

— Балакаем, синең кавырсының да катмаган икән ич әле. Диюнең бакчасында бер алмагач бар, шунда ук күле дә бар. Шул алмагачның алмасын ашап, күленнән су эчкән кеше җир йөзендә бер баһадир була. Син өч ай буена иркенләп шул алмагачтан алма ашап, күленнән су эч. Шуннан соң мин сине яңадан бу шарны күтәреп сынап карармын. Дию унике айлык юлга киткән иде, янә дә ун айсыз кайтмый. Бу көнгә син әле баһадир түгел, сиңа ышанып юлга чыгар хәлем юк,— ди.

Ананың сүзен тыңлап, егетебез өч ай буена шунда алмагачтан алма ашап, күлдән су эчеп ятканнан соң янәдән килеп кергәч, анасы моңа шарны күтәреп карарга куша.

— Дию үзе буш вакытларында шул шарны алып чыгып, әнә теге биек тауның башына ыргытып җибәрә дә, шар төшкән чагында сыңар кулы белән тотып алып, күккә чөя иде,— дип хәлне төшендереп бирә, ди.

Әлеге сүзләргә яман гарьләнеп, шарны ачу белән ала да егет, тау башына ыргытып торып җибәрә. Әмма тәгәрәп төшкәндә тотып кала алмый — шар моны бәреп ега да үз юлына тәгәри, тау итәгенә барып төшә, ди.

Анасы бу хәлне күреп:

— Балакаем, инде кавырсының яңа гына ката башлаган икән, янә берәр ай ирек алсаң, үзеңә бераз көч керер,— ди.

Бакчадагы алмагачтан алма ашап, күленнән су эчеп, ай ярымлап торганнан соң анасы:

— И балакаем, инде тагын берәр сынап карыйм, вакытлар кыскарып бара,— дип, улына шарны яңадан ыргытырга куша.

Улы шарны ыргытып торып җибәрә дә, төшкән чагында сыңар кулы белән генә тотып алып, яңадан тауның башына ыргыта, кабат тотып алып, яңадан ыргытып җибәрә.

Бу хәлне күреп, анасы:

— Инде хәзер куәтең диюнеке белән тигезләнде. Аның белән көрәшерлек көчең бар. Инде алтын сарай саклап ятудан файда чыкмас, улым. Аңсыздан дию кайтып керсә яки туганнарыннан берәрсе килеп чыкса, харап булуыбыз бар,— ди.

Шуннан соң анасы тагын бер сарайга алып барып, аның ишеген ачып, икәүләшеп шундагы зур бер һава көймәсен чыгаралар да тузаннарын каккалап, ватылган җирләрен төзәткәләп, сәфәргә әзерләп куялар. Аннары ашыйлар-эчәләр дә, сарайдан кырык бер кызны да үзләре белән алып, әлеге очкычка утырып, һавага күтәреләләр, ди.

Киткән чакта падишаһ хатыны, әфсен укып, алтын сарайларны вә бакчаларны бер алтын күкәй итеп йомарлап, кесәсенә сала. Һава көймәсе белән иртәдән кичкә хәтле генә очалар да болар

көмеш сарай турысына килеп җитәләр. Егет, анасына карап:

— Әни, без бераз монда туктыйк әле. Син машинаның телен бор. Монда безнең кебек үк адәми затлар бар, аларны да алып очарбыз,— ди.

Көмеш сарайда боларны тансыклап көтеп торалар икән. Шунда ял итеп, кунак булып, бу сарайны да, алтын сарайлар шикелле, көмеш күкәй итеп йомарлап кесәләренә салалар да, андагы кырык бер кызны да үзләре белән алып, тагын һавага күтәреләләр.



Бераз очып барганнан соң бакыр сарай турысына житәләр болар. Бу вакыт бакыр сарайның диюе кайткан була. Шунлыктан боларны һичкем каршы чыгып алмый.

Бу хәлне күреп падишаһ хатыны улына:

— Китик, без моннан, улым, яхшы чакта,— дип киңәш итә.

Мәгәр улы моңа риза булмый:

— Әни, монда кермичә ярамый, монда минем кәләшем! Шулкадәр алмалар ашап, сулар эчеп инде бу диюдән куркып торыр хәлем юк,— дип, машинадан төшә дә бакыр сарайның ишегеннән кереп китә.

Остабикә дә, моның кәләше дә, башка кол кызлар да аны үкереп каршы алалар:

— Бәхетебез юк икән, диюебез кайтты. Җир астында фәлән сарайда йоклап ята. Уяна калса, сине дә, безне дә харап итәр,— диләр.

Диюнең кайда йоклаганын сорап, шунда юнәлә шаһзадә. Ни күрсен, жиде башын жиде якка салып, дию гамьсез генә йоклап ята, имеш. Керүгә алмас кылычын чыгарып, бер башын кисеп төшерим, дигәндә генә, исенә килеп: «Тукта әле, йоклаган кешене кем үтерер. Мин моны уятыйм да көчемне сыныйм — сугышып карыйм. Үлсәм — хак үлем булыр»,— дип, диюнең баш очында бераз утыра. Дию һаман уянмагач, сарайга кире кереп, диюнең хатынына:

— Бар, диюегезне уят. Аның белән көрәшеп, көч сынашып карыйсым килә,— ди.

Диюнең хатыны:

— Адәми зат килгәндә, аны уята торган бер без бар. Син шул безне ал да табан астына тыгып бута. Шуны сизеп, ул уяныр. Уянгач та тәмле сүзләр сөйли башлар. Әмма син аның алай йомшак сөйләвенә карап алданма. Ул бик хәйләкәр. Ул йомшак торган саен, син каты тор. Юкса, алдар үзеңне. Кара аны, алдана күрмә,— ди.

Шаһзадә безне алып диюнең бер табанына тыгып бутый — дию берни сизми. Икенче табанына ныграк тыгып бутавы була — дию үкереп уяна:

— Кая, адәми зат килгән икән. Нигә кунак итмисез? — дигән була.

Шаһзадә моңа каршы:

— Мин ач түгелмен. Мин бары синең каныңа сусап кына килдем. Кая, тор, әйдә чыгабыз да алышабыз! — ди.





Анының бу сүзләренә диюнең хәтәр ачуы килә дә урыныннан сикереп тора. Алар шундук мәйданга чыгалар, алышырга тотыналар. Ныклап торып алыша торгач, тигез җирләр түмгәккә, түмгәкле җирләр сазламыкка әйләнә. Озаклап алыша торгач, егет диюне күтәреп алып ыргытуы була — дию тезенә кадәр җиргә бата. Диюнең ачуы кабарып, сикереп торып, егетне җиргә күтәреп бәрүе була — егет билдән җиргә бата. Моңа ифрат гайрәте чигеп:

— Юк, бездә алай бәрмиләр, бездә менә болай бәрәләр,— дип диюне күтәреп алып җиргә бәрүгә була — дию билдән җиргә бата.

Шулай итеп, нихәтле генә алышмасыннар, һич кенә дә берсен-берсе җиңә алмый болар. Соңра дию:

— И адәми зат, инде без алышмадык түгел, алыштык, мәгәр беребез дә җиңә алмады. Мин бик ачыктым, бераз ашап чыгыйм,— ди.

Шаһзадә аңа:

— Оятсыз, үзең генә ашар идеңмени?! Мин дә тик тормадым, мин дә арыдым. Мине дә алып кер,— ди.

Риза булмый хәле юк диюнең, алып керә.

Бакыр сарайда ике өстәл булып, берсенә дию үзе утыра, икенчесенә килгән кунакны утырта икән. Керү белән, дию хатыныннан ашарга-эчәргә китертә. Диюнең ике төрле суы булып, берсе хәл кертә, икенчесе хәл китәрә икән. Диюнең хатыны кай арада барысын аңлап, диюгә хәл китәрә торган суны, кунакка исә хәл кертә торган суны салып бирә. Дию эчә дә — бөгелеп кенә төшә. Егет эчә дә — отыры батырланып китә. Эшне бик тиз сизеп ала дию, хатынына ачу белән:

— Сез мине бүген харап итәсез икән,— ди. Әмма аны бәреп үтерергә кыймый — кунагыннан курка.

Соңра дию белән шаһзадә сахрага чыгып, яңадан алыша башлыйлар. Шаһзадәнең диюне күтәреп алып ыргытуы була — дию муеныннан җиргә күмелә. Шуннан инде шаһзадә алмас кылычын чыгарып, диюнең җиде башын җиде җиргә кисеп төшерә дә сарайга юнәлә.

Җиңүчене күреп, хатын-кызлар бик куаналар:

— Бу көнне дә күрәсебез бар икән! — диләр, егеткә рәхмәтләр укыйлар.

Шаһзадә аларга:

— Әйдәгез, инде моннан китәбез,— ди.

Кәләше аңа:

— Тукта, монда тагын безнең кардәшләребез бар, аларны да коткар инде,— ди.

Шуннан болар сарайны тикшереп чыгарга булалар. Бер бүлмәне ачып җибәрсәләр — бүлмә тулы карт-коры икән. Диюнең гадәтен белгәнгә, симезебезне тотып ашар инде, дип, котлары алынып, кача башлыйлар. Шаһзадә аларга:

— И абзыйлар, сез миннән бер дә шикләнмәгез. Мин үзем дә сезнең кебек үк адәми затмын, сезне коткарырга килдем, әйдәгез, чыгыгыз,— ди.

Янә дә бер бүлмәне ачып җибәрсә — анда карчыклар ята икән. Алар да куркышып:

— Менә бу симез! Әнә ул симезрәк! — дип бер-берсенә күрсәтә башлыйлар.

Шаһзадә аларга:
— Курыкмагыз, әйдәгез, чыгыгыз, мин сезне коткарам,— ди.
Бераз ял итеп алганнан соң, ау мылтыгын алып, якындагы урманга кошлар атарга дип юллана шаһзадә. Моны беркем дә абайламый кала.
Ул арада анасы:
— Монда хәтсез озак юандык,— дип, ашыктырып, һава көймәсенә кызларны утыртып, күккә күтәреләләр.
Ике көн киткәннән соң гына шаһзадәнең юклыгын абайлыйлар. Кире кайтырлар иде — диюнең нәселеннән берәрсе очрап, үзебезне һәлак итеп ташламагае, дип шикләнәләр һәм очалар да очалар. Зур бер шәһәргә житәрәк кенә жиргә төшеп, көмеш вә алтын сарайларын җәеп, шаһзадәне көтмәк булалар.
Урманда бераз йөреп, төрле кошлар атып, кесә-кәләпүшләренә җиләкләр җыеп, хатынына булыр дип куанып, бакыр сарайга кайтып керсә, шаһзадә ни күзе белән күрсен — бакыр сарайның эчендә һичбер җан иясе калмаган.
Ашыйсы килеп, бүлмәдән бүлмәгә кереп йөргәндә кечерәк кенә бер бүлмәгә туры килә бу. Әлеге бүлмә уртасында бәләкәй генә өстәл булып, ул өстәл өстендә күк кисәге төсле зәңгәрсу бер әйбер белән карыш буйлы гына чыбык ята икән. Әлеге чыбыкны кулына алып, бу ни эшкә ярый икән инде, диеп, әлеге күк кисәгенә бәреп карый бу. Шундук аның каршысында гыйфрит пәйда була:
— Ни боерасыз? — ди.
Чыбык белән күк кисәгендә хикмәт барлыгын аңлап, шаһзадә гыйфриткә:
— Минем аналарым моннан киткәннәр икән, берүзем калганмын. Алар янына күпме вакытта илтеп житкерерсең? — дип сорый.
Гыйфрит аңа:
— Өч көндә илтеп житкерермен,— дип җавап кайтара.
Моны озакка санап, шаһзадә чыбык белән әлеге күк кисәгенә яңадан суга. Икенче гыйфрит, моннан шәбрәге пәйда була:
— Ни боерасыз? — ди.
Шаһзадә:
— Мине аналарым янына күпмедә илтеп житкерерсең? — дип сорый.
Гыйфрит аңа:
— Бер көндә,— дип җавап кайтара.
Моны да озакка санап, шаһзадә чыбык белән әлеге күк кисәгенә яңадан суга. Өченче гыйфрит пәйда була:
— Ике сәгать эчендә житкерермен,— дип җавап кайтара.



Шаһзадә шатланып, моның сыртына менеп атлана. Инде турыдан-туры сарайга барып керсәм, килешмәс, алар мине кызык иткән кебек, үзләрен дә кызык итимче дип, гыйфриткә:

— Син мине туры сарайга илтмә, шәһәрнең читенә төшер,— дип әмер бирә.

Җәяүләп кенә шәһәргә килеп кергәч, бер картның артына тагыла. Карт кая барса, бу да шунда бара. Шактый барганнан соң, ул карт фәкыйрь генә бер өйгә керә. Аның

артыннан керсә, күрә шаһзадә — карт бер итекче икән. Исәнләшеп сүз куша:

— И бабай, син бер бик шәп итекче икәнсең. Тереклек итүе читенгә килә икән үзеңә. Минем сиңа бер йомышым бар. Шуны үтәсәң, үзеңә мең тәңкә бирермен,— дип өметләндерә.

Карт әйтә:

— Әгәр кулымнан килерлек эш булса, нигә эшләмәскә,— ди.

Шаһзадә аңа:

— Беләсеңме, шәһәрнең читендә ике сарай бар, шунда бер кызны күреп гашыйк булдым. Син шуларга яучы булсаңчы,— ди.

Карт шуннан шәһәрнең читенә чыгып, сарайга юнәлә. Кыз да, бүген үзенә бер кеше киләсен төшендә күреп, сизеп тора икән. Сарайга килүче картны ул каршы чыгып ала. Карт аңа:

— И кызым, миндә бер кунак егете бар. Ул үзеңне күреп гашыйк булган бит. Менә мине яучы итеп җибәрде. Инде үзең ни дип әйтерсең? — ди.

Каршы килми кыз:

— Ярый,— ди.— Тик минем калымым зур булыр, адәм кулыннан килә торган эш түгел. Әгәр дә мәгәр шуны булдыра алса — мин аныкы, ул минеке. Бер күлмәк бүләк итсен: ул күлмәкнең бер генә дә җөе булмасын, өстемә таман гына булсын, бармактагы балдактан үтәрлек булсын да йомарлагач учка сыярлык булсын. Янә дә бер кәвеш бүләк итсен: ул кәвешнең бер генә дә кадагы булмасын, аягыма тап-таман булсын,— ди, үзе эченнән генә, болар минем иремнән гайре берәүнең дә хәленнән килмәс, дип уйлый.

Карт аңа:

— Бик яхшы,— дип, кайта да кунагына хәлне сөйләп бирә.

Шаһзадә бер дә кайгырмый:

— Ярый, бабай, син шунда торып тор, мин барып алып кына килимче,— ди дә сахрага, эт тавышы ишетелмәстәй җиргә китеп, кесәсеннән тылсымлы әйберләрен чыгарып, әлеге чыбык белән күк кисәгенә сугуы була — гыйфрит пәйда була.

— Ни боерасыз? — ди.

Шаһзадә аңа:

— Шундый-шундый күлмәк белән шундый-шундый кәвешне ничә сәгатьтә табып китерерсең? — ди.

Гыйфрит:

— Өч сәгатьтә табып китерермен,— ди.

Өч сәгать көтүе озак булыр дип, икенче гыйфритне чакыра шаһзадә. Анысы:

— Бер сәгатьтә җиткерермен,— дигәч, янә суга — өченчесен чакыра.

Монысы:

— Ярты сәгать эчендә китереп алдына куярмын,— дип вәгъдә итә.

Мин шушында көтәрмен,— дип, гыйфритне җибәрә шаһзадә.

Гыйфрит шундук алтын сарайга барып, кызның буениңен вә аягын үлчәп, кушылган нәрсәләрне табып китерә. Егет боларны бик ошатып, рәхмәтләр әйтеп, алып кайта да картның кулына тоттыра.

Карт боларны алтын сарайга илтеп, кызга тапшыра. Күлмәкне дә, кәвешне дә кыз шундук киеп караса — имештер, тап-таман. Бу эшләрне дию мәмләкәтендә булмаган бер генә кеше дә башкарып чыга ала да торган түгел: шул икән, минем киявем икән, дип фикер йөртә.

Картка исә:

— Кичкә килерсез, рәхим итегез,— ди.

Кичке якта карт белән шаһзадә икәүләшеп алтын сарайга киләләр. Боларны барчасы да чыгып каршы алалар. Анасы белән күрешә егет, башкалар белән күрешә, һәммәсе дә бик сөенешеп, бергә-бергә сыйланып алалар, вәгъдә иткән акчаны биреп картны озатып калалар.



Шуннан инде алтын вә көмеш сарайларны йомырка ясап, кесәгә салалар да һава көймәсенә кереп утыралар.

Ана кеше үзенең юлдашларына:

— Инде улым һәммәгездән элек кереп утырсын,— дип әмер бирә.

Оча торгач моның агасы калган базга җитәләр. Агасы боларның килгәнен күрсә дә, кем килгәнен белми бит әле, сагая кала. Инде болар икәнне күргәч, каршы алып, сөйләшеп тә сайрашып, бергә-бергә сәфәрләрен дәвам иттерәләр, ди.

Янә дә бераз очканнан соң Ак бүренең урманына килеп җитәләр дә бер бик әйбәт аланга төшәләр. Болар һава көймәсеннән төшеп, ашап-эчеп утырган чагында, Ак бүре моны сизенеп, бик матур егет сурәтенә кереп, яннарына килә. Шундый чибәр егет килеп күрешкәч, һәммә кызның күзе уттай яна. Шаһзадә моны бик ныклап сыйлый-сыйлый да:



— И дустым Ак бүре, сиңа әйтер сүзем шулдыр: менә монысы минем кәләшем,— ди, янә өчесенә ымлап,— болары агаларыма багышладым. Калганнары да бик чибәрләр. Күңелеңә хуш килердәен үзең сайлап ал инде,— ди.

Ак бүре сайлап алган кыз да: «Бигрәк чибәр егеткә туры килдем», дип, бик сөенә.

Соңра болар, саубуллашып, янә сәфәрләрен дәвам иттерәләр. Ничәмедер көн очканнан соң зур гына бер





шәһәргә тап булалар. Көмеш сарайның хуҗасы — тугыз башлы диюнең хатыны:

— Бу бит минем шәһәрем! — дип, шаһзадәгә күп итеп рәхмәтләр әйтеп, үз шәһәренә төшеп кала. Шундагы падишаһның хатыны икән, кайтып төшкәч, бик шатланышып, бик рәхәтләнеп гомер кичерәләр.

Янә бераз очып барганнан соң болар тагын зур гына бер шәһәргә тап булалар. Җиде башлы диюнең хатыны:

— Бусы минем шәһәрем! — дип, шаһзадәдән рөхсәт сорап, рәхмәтләр укып, төшеп кала.

Шаһзадә үзенең кәләшеннән һәм агаларына атаган кызлардан башкаларына, үзләре бик сорагач, шунда калырга рөхсәт бирә.

Шуннан инде болар әлләни озак бармыйлар, үз шәһәрләренә дә кайтып җитәләр. Дүрт-биш чакрым калганда, көн бик кичкә авышкан булганга, инде иртәнге якта кайтып керербез, дип, куныл калалар. Падишаһның җир йөзендә бер чибәр хатыны кесәсенә күкәй итеп салган алтын сарайларны, бакчаларны чыгарып, нәкъ дию шәһәрендәге шикелле иттереп корып җибәрә.

Һәммә кеше йокларга яткач, диюдән алып кайткан балдагын бармагыннан сала да шуны сызгыртып торып җибәрүе була — җирдәге чүпкә сан бар — гыйфриткә сан юк, шулкадәр күбәүләшеп киләләр дә моның янына җыелышалар.

— Ни боерасыз? — диләр.

Падишаһның җир йөзендә бер чибәр хатыны:

— Менә бу сарайдан шәһәргә хәтле таң атканчы алтын күпер сузыгыз. Ул алтын күпернең ике ягыннан ике елга: бер — тегеләйгә, берсе — болайга табан агып торсын. Ул елгалар өстендә күз күрмәгән, колак ишетмәгән үрдәкләр бакылдашып, казлар каңгылдашып йөзеп йөрсен. Елганың ике ярында алмагачлар үсеп утырсын. Алмалары пешеп суга коела торсын. Аны йөзеп йөргән кошлар ашый торсын. Ул күпернең дә өстендә җигүле пар ат булсын. Арбасының көпчәкләре алтыннан булып, чайкалдырмый-тибрәндерми йөртерлек булсын. Ат башында адәм куркырлык зат — чуеннан да кара, зур мыеклы гыйфрит булсын. Шуларны таң атканчы тәмам итегез,— ди дә үзе йокларга ята.

Өч-дүрт сәгать йоклый микән, юк микән, гыйфритләр килеп моның ишеген кагалар. Чыгып караса — бар да нәкъ



менә үзе дигәнчә эшләнгән. Гыйфритләрне үз юлларына җибәреп, бераз вакыт узганнан соң таңнар ата.


Таңнар атып яктыргачтын, падишаһ торып чыкса, ишек төбеннән сузылып киткән алтын күперне күреп, хафага кала:

— Аh, хараплар булганбыз икән, су баскан ләбаса! Чыгыгыз, тиз булыгыз, сарайны коткарыгыз! — дип вәзирләренә әмер бирә.

Вәзирләр чыгып карасалар — алтын күпер, имеш.

— И падишаһыбыз, су түгел ул. Озакламый бер-бер хәбәр булыр. Йә хатының, йә улларың кайтыр,— дип сөендерәләр.

Падишаһ затлы киемнәрен киеп, тәхеткә утырып, көтә башлый. Шул чагында гыйфрит аңа матурлап язылган хат китереп тапшыра. Хатта болай дип язылган була:



«Падишаһыбыз әгъзам хәзрәтләре! Сезләргә чуктин-чук сәламнәремне күндерәмен. Сәлам соңында әйтәсе килгән сүзем шулдыр: Аллага шөкер, без исән-имин кайтып җиттек. Янә дә үтенечем шулдыр: сәгать унда ошбу күпернең аргы башында кардәш-кабилә, мулла-мунтагай белән бергә-бергә көтеп торсагыз иде. Ошбу гыйфрит сезләрне безләргә кунаклый алып килер иде».

Сәгать унга кадәр падишаһ агай-энеләрен җыеп, затлыдан-затлы киемнәрен киеп, күпер башында көтеп тора. Болар янына пар ат җигеп гыйфрит килеп туктый:

— Әйдәгез, утырыгыз,— дип, боларны утырта да шул ук минутта алтын күпер буйлап алтын сарайга китереп тә җиткерә.

Падишаһның уллары вә киленнәре боларны каршы алып, хөйран зурлап, ашатып-эчертеп, ашау-эчү тәмам булганнан соң, килгән кунакларга кайтырга рөхсәт бирелеп, алар өйләренә гыйфрит арбасына утырып кайтып китәләр. Монда падишаһ бары мулла-мунтагай белән, уллары белән үзе генә торып кала. Шуннан падишаһның төпчек малае атасына анасын сау-сәламәт алып кайтканын әйтә, аны яңадан никахлап алуын үтенә. Моңа падишаһ та риза булып, шул ук сәгать никах укытып җибәрәләр. Ун көн уен ясап, тугыз көн туен ясап, тумаган туры бияне суеп, шуның шаңгырдатып торган бер сөяген падишаһ үзенең хатыны белән көн дә тотып кимерә, ди, төн дә тотып кимерә, ди.

Шуннан соң падишаһ җир йөзендә бер чибәр хатынын үзенең сараена алып кайтып китә дә, болар шунда гөрләтеп яшиләр, ди.

Падишаһның төпчек малае исә агаларын да алып кайткан кызлар белән никахландырып, утыз көн уен ясап, кырык көн туен ясап, агалары да хатыннарын өйләренә алып китәләр, ди.

Шаһзадәбез үзенең хатыны белән әлеге дә баягы алтын сарайда торып кала, ди. Тыныч кына гомер кичергән бер мәлдә җиде башлы диюнең хатыны да, тугыз башлы диюнең хатыны да кунакка чакырып хат җибәрәләр, ди. Шул ук сәгатьтә шаһзадә хатыны белән аларга кунакка барып чыга. Анда боларны бик зурлап каршы алып, һәйбәтләп кунак итеп, хәтсез күп бүләкләр биреп, кадерләп сараена озатып җибәрәләр. Шаһзадә үзенең алтын сараена кайтып, хатыны белән шунда әле дә булса рәхәт гомер сөрә, ди.

Китап Татарстан Республикасы Президенты каршында оештырылган Мәдәният үсешенә булышлык итү фондының ярдәме белән бастырылды



КЕЧЕ ЯШЬТӘГЕ МӘКТӘП БАЛАЛАРЫНА

БЕЛЫЙ ВОЛК

татарская народная сказка

(на татарском языке)

Редактор Җ. С. Миннуллин. Нәфасәт редакторы Ш. К. Насыйров.
Корректор Р. Ф. Мәрданов.
Производствога тапшырылды 25.12.92. Басарга кул куелды 1.04.93.
Офсет кәгазе № 1. Тираж 30 000. Зак. Я-180.
«Заман» нәшрияты. 420022. Казан. Г. Тукай ур., 74.
Татарстан «Полиграфия ассоциациясе». 420066. Казан, Декабристлар ур., 2.

© Фәридә Хәсьянова, рәссам, 1993